УДК 398

*И.Г. Закирова*

# ФОЛЬКЛОРЧЫ ФЛОРА ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ

Статья посвящена научному творчеству татарского ученого-фольклориста Ф.В. Ахметовой-Урманче, обозначены главные направления ее научных исследований, актуальные для татарской фольклористики по сей день. Известному фольклористу, старшему научному сотруднику отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ, кандидату филологических наук, лауреату Государственной премии им. Г. Тукая, заслуженному деятелю культуры Республики Татарстан Флоре Вагаповне Ахметовой-Урманче 23 мая 2025 года исполнилось бы 90 лет. Ф.В. Ахметова-Урманче является автором многочисленных статей, посвященных эпическому творчеству татарского народа. Особое место в научной деятельности ученой занимает работа по составлению и изданию томов «Дастаны» и «Баиты» академического свода татарского народного творчества.

**Ключевые слова:** Ф.В. Ахметова-Урманче, дастаны, татарский эпос, баиты, текстологическая работа.

The article is devoted to the scientific work of the famous Tatar scientist-folklorist F.V. Akhmetova-Urmanche, the main directions of her scientific research, relevant for Tatar folklore studies to this day are outlined. The famous folklorist, senior researcher of the folk art department of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, candidate of philological sciences, laureate of the State Prize named after G. Tukay, honored cultural figure of the Republic of Tatarstan Flora Vagapovna Akhmetova-Urmanche would have turned 90 on May 23, 2025. F.V. Akhmetova-Urmanche is the author of numerous articles devoted to the epic creativity of the Tatar people. A special place in the scientific work of F.V. Akhmetova is the work on the compilation and publication of the volumes “Dasans” and “Baity” of the academic collection of Tatar folk art.

**Keywords:** F.V. Akhmetova-Urmanche, dastans, Tatar epic, baits, textual work.

Дастаннарны җыю һәм өйрәнү буенча зур эш башкарган фольклорчы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Флора Әхмәтованың Татар фольклористикасы тарихында үз урыны бар. Быел эпос белгече Флора Әхмәтова-Урманчега 90 яшь тулыр иде. Мин Институтның халык иҗаты бүлегенә 1995 елда килдем, һәм без ун елдан артык Флора апа белән коллегалар булдык. Шуңа күрә бу мәкаләдә дә аны, үзенә эндәшкән вакыттагы кебек, Флора апа дип тә атыйм.

Флора Ваһап кызы Әхмәтова 1935 елның 23 маенда Төмән өлкәсенең Тубыл районы Күкрәнде авылында укытучы Габделваһап абзый гаиләсендә туа. Алар авылның хөрмәтле нәселләреннән берсе булып, әтисенең әтисе Туктабай да укымышлы кеше – мулла була.

Әтисе Габделвaһап бала чагыннан ук үзенең уйлау сәләте, башлы булуы белән бөтен авылдашларын шаккатыра. Флора апа сөйләве буенча, әтисе рус мәктәбендә белем ала, Троицкида 1915 елда ирләр өчен ачылган педагогик училищены тәмамлый. Троицкидан кайткач, ул укытучылык хезмәтен башлый, киң карашлы, заманы өчен тирән фикерле мөгаллим авыл балалаларына белем бирүгә үтә җитди карый. Әмма бу затлы кешенең тормышында да кара киртәләр корылган була. Тубыл Милли Шурасы рәисе итеп сайланган, халыкка киңәшкә килгән, авылдашлары ихтирам иткән Габделвaһап абзыйны Сталинның шәхес культы елларында кулга алалар. Ул төрмәдән Күкрәндегә – өенә каты авыру хәлдә, үләргә генә кайтарыла. Флора апаның әнисе тагын да иртәрәк дөнья куеп, кыз бала 8 яшендә тома ятим кала. Дүрт баланы әниләренең Фәрә исемле (Фәхриҗамал) туганнан туган сеңлесе үстерә. Үзе дә яшь, кияүгә дә чыкмаган кыз һәрберсен укыта, олы тормышка озата. Тубыл педагогия институтын сугыштан соң тәмамлаган абыйсы Әдипкә (1930 елгы) ияреп, Флора 6 нчы класстан соң Обь елгасы буендагы салкын-шыксыз Лабытнанги шәһәренә китә һәм рус мәктәбенә урнаша. Татар мәктәбеннән соң балага укуын русча дәвам итү дә, туганнарыннан читтә булу да бик авыр бирелә. Бер-ике айдан ул үзен кире Күкрәндегә кайтаруны сорый. Авылга кайтып, 7 класс бетереп – башта Тубыл татар педагогия училищесында, аннан соң Төмән педагогика институтында укый. Институтны тәмамлаганнан соң, Ханты-Манси округының Сургут районында балалар укыта.

Институтның 2021 елгы комплекслы экспедициясе вакытында Флора апа туып-үскән Күкрәнде авылында без дә булдык. Сазлыклар эчендә кечкенә генә утрау булып урнашкан бу авылга җәен – көймә белән, кышын боз өстеннән генә кереп була. Шуңа карамастан, авыл хәзер дә исән, телне һәм гореф-гадәтләрне саклап яшәвен дәвам итә. Күкрәндедә, Флора апаның әтисе һәм бертуганнары тырышлыгы белән, 1940 елда яңа мәктәп бинасы салына. Зур тәрәзәле, якты бу бина – хәзерге вакытта да эшләп торган мәктәп. Бина Әхмәтовлар проекты буенча салынган һәм яхшы уйланылганлыгы белән сокландыра. Һәр кабинет коридордан ягыла торган мич белән җылытыла, мич үзе эчке яктан күренми, салкын кышларда укучы көн дәвамында мич ягучыны да, утын ташучыны да күрми. Себер салкын кышлары белән мәгълүм булса да, биредә кояшлы көннәр дә күп. Аяз көннәрдә кабинетны зур тәрәзәләр аша кояш та җылыта. Гомумән, авыл тарихында да, мәктәп тарихында да Ваһап Әхмәтов һәм аның уллары-кызлары тирән эз калдыралар. Авылның тел-мәдәниятне саклап, бүгенгәчә яшәп килүендә шушы мәктәпнең, аның белән җитәкчелек иткән Әхмәтовларның роле зур булу беркемдә дә шик уятмый. Мәктәп ачылган көннән башлап, биредә эшләгән укытучылар – татар әдәбиятына, мәдәниятенә гашыйк шәхесләр. Алар укучыларда да туган телгә, әдәбиятка, халык иҗатына мәхәббәт уятырга тырышалар. Күкрәнде мәктәбендә язучы Якуб Зәнкиев математика укыта. Шушы

авыл, аның кешеләре әдипнең «Иртеш таңнары» романына да прототип булып кереп китәләр. Авыл халкы, туганнары Флора апаны җылы сүз белән искә алдылар. Ул бирегә туганнары белән очрашырга да, фольклор материаллары тупларга да еш кайта. Мәсәлән, Күкрәнде авылында Шәрифҗамал Халитовадан (1907 елгы), Кави Ибраһимовтан (1914 елгы), Зәкия Ильясовадан (1956 елгы) «Алыпмәмшән» дастанының вариантларын, Галимә Кәримовадан (1888 елгы) «Бүри хан» дастаныннарын язып ала һәм фәнни әйләнешкә кертә.

Күкрәндедән чыгып киткән кызның урау юллар белән Казанга килеп төпләнүендә, соңрак тормышын фән белән бәйләвендә атаклы галимә, диалектолог Диләрә Гариф кызы Тумашеваның роле зур. Диләрә ханым чакыруы буенча, Флора аспирантурага укырга керә. 1968 елда «Фольклор һәм хәзерге татар прозасы» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклагач, ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фольклор секторында эшли башлый, халык иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнә. Җырлы-дастанлы Себер ягыннан килгән кыз өчен филология фәненең бу өлкәсе аеруча якын була. Галимәнең исеме вакытлы матбугат битләрендә беренче тапкыр 1964 елда «Совет әдәбияты» журналында күренә. 1965 елдан газета-журналларда татар фольклорына багышланган мәкаләләре басыла башлый. Аның татар фольклористикасындагы дастан, бәет жанрларына, әдәбият һәм фольклор бәйләнешләрен яктыртуга багышланган мәкаләләре фәнни җыентыкларда, вакытлы матбугат битләрендә еш дөнья күрә.

Флора апа татар эпосын өйрәнүгә бөтен көчен куя. Ул 1976 елда Алма-Ата шәһәрендә узган тюркология конференциясендә татар фольклорындагы дастан жанры турында чыгыш ясый. Татар дастаннарын өйрәнүдә 30 елдан артыкка сузылган тынлыктан соң, 1978 елда эпоска багышланган «Дастаннар» дигән беренче күләмле мәкаләсе «Татар фольклоры жанрлары» җыентыгында басыла. Шул ук елда Элиста шәһәрендә узган конференциядә татар дастаннарын «Джангар» белән чагыштырма планда өйрәнеп, үзенең нәтиҗәләрен фәнни даирәгә тәкъдим итә, Якутск шәһәрендә узган конференциядә якут һәм татар эпик бәйләнешләренә тукталa. 1979 елда Улан-Удэ шәһәрендә узган «Себер халыкларының эпик иҗаты» дигән фәнни конференциядә «Алпамыш» дастанының татар версиясе турында чыгыш ясый. Гомумән бу елларда ул СССР шәһәрләрендә узган конференцияләрдә актив катнаша. Чикләр ачылганнан соң, Флора апа татар фольклорын дөньяга танытуга да зур хезмәт куя. Татар дастаннарын өйрәнүгә багышланган мәкаләләре белән халыкара симпозиумнарда, чит илләрдә оештырылган фольклор форумнарында да катнаша. Мәсәлән, Америка фольклорчылары алдында (Мэдисон, 1990) татар халык иҗаты турында чыгыш ясый.

1984 елда «Татар халык иҗаты» академик җыентыгының Флора Әхмәтова төзегән «Дастаннар» томы дөнья күрә. Бу татар дастаннарын төрле архивлардан, кулъязмалардан һәм басма чыганаклардан

туплап чыгарган беренче җыентык һәм шактый еллар бердәнбер хезмәт була һәм тиз арада таралып бетә. Галимә әлеге җыентыкны, тулыландырып, 2004 елда «Татар эпосы. Дастаннар» дигән исем белән яңадан чыгара.

Татар фольклорының Флора апа өйрәнгән тагын бер юнәлеше – бәетләр. Ул «Татар халык иҗаты» академик томнарының «Бәетләр» томын төзүдә дә катнаша. Борынгы һәм Октябрьгә кадәрге чор бәетләрен туплап, томны И. Надиров һәм Л. Җамалетдинов белән бергәләп төзи. Соңрак әлеге томны тулыландырып, яңа кереш сүз һәм искәрмәләр белән «Татар эпосы. Бәетләр» җыентыгын (2001) бастыра. Флора апаның Себер татарлары фольклорын туплаган соңгы җыентыгы – «Джаным» дип исемләнгән антология – 2016 елда Мәскәүдә, аның вафатыннан соң, атаклы фольклор тәрҗемәчесе А.В. Преловский тырышлыгы белән дөнья күрә. Бу җыентыкларга Флора апаның Себернең төрле өлкәләрендә узган фольклор экспедицияләре вакытында язып алган дастан, бәет, әкият, җыр текстлары да кергән.

Галимәнең тагын бер фәнни эшчәнлеге гарәп язулы хезмәтләрне кирилл алфавитына күчереп, халыкка кайтару белән бәйле. Ул Рәшит Ибраһимовның «Дәүре галәм» һәм «Тәрҗемәи хәл» дигән хезмәтләрен кириллицага күчереп бастырып, халыкка бу шәхесне танырга ярдәм итә.

Флора Әхмәтова – күренекле скульптор, рәссам Бакый Урманченың хатыны (сүз уңаеннан, ире аңа гомере буе Айгөл дип эндәшә). Ул Бакый ага белән ничек танышулары турында сөйләргә ярата иде. Алар 1966 елда Институт оештырган Халыкара конференциядә Флора апаның чыгышыннан соң танышалар. Бакый Урманче японкага охшаган кызны бик игътибар белән тыңлый. Рәссам аның күпсанлы портретларын гына язып калмый, беренче күрүеннән үзенең музасы итеп сайлап, аңа шигырьләрен дә багышлый.

Кафедрада бер кыз
Тәнкәе ак, чәчкәйләре
шомырт кара
Күзләре, кашлары
кара шундый,
Йөзе тулган ай.
Сокланып, сокланып карыйм.
Татар фольклоры хакында сүз бара.
Үзе фольклор бу,
Үзе халык җыры, үзе дастан,
Сөбхан, сөбхан, сөбхан!

Бу урында Флора апаның тагын бер сәләтен искә төшермәсәк, мәкалә тулы булмас иде. Ул бик матур җырлый, һәм бу сыйфаты белән халык иҗаты бүлеге мәҗлесләренең күрке була иде. Һәр бәйрәмдә фольклорчылар Флора ападан «Кара елан» җырын җырлаталар. Татар дастаннары көйләре-назымнарны да Флора апа кебек башка-

ручы сирәк булгандыр. Бу көйләр хәзер дә Флора апа белән Бакый Урманче язмаларында саклана. Флора ханым рәссам һәм скульптор Бакый Урманче иҗатын популярлаштырып, бу бөек шәхеснең иҗатына багышланган өч альбом әзерли, 1999 елда рәссамның шәхси музеен ача. Музей фондын да Флора апа үзе туплый. Мемориаль комплекс һәм сәнгать күргәзмәсе принципларын берләштергән әлеге музейда останың иҗади эшчәнлегенең барлык якларын күзалларга мөмкинлек биргән экспонатлар – шәхси әйберләре, йортыннан һәм остаханәсеннән җиһазлар, һәм, әлбәттә, картиналар, графика һәм Б. Урманче иҗат иткән мәрмәр сыннар һәм скульптуралар урын алган. Б. Урманченың иҗат мирасының төп өлеше шушы музейда саклана.

Аларның уллары Айдар хәзерге вакытта, әтисеннән алган сәләтен дә кушып, уникаль агач эшләнмәләр җитештерү белән шөгыльләнә.

Язмамны Бакый Урманченың икесенең дә эшчәнлегенә бәя биргән шигыре белән тәмамлыйсы килә:

Айгөл генәсе,
Җиһанның бер генәсе.
Гомеремнең бизәге,
Рәхәте син генәсе.
Икебез дә без – дәрвишләр,
Хыял, сәнгать – нәни генә безнең эшләр.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Закирова Ильсеяр Гамиловна,***
*доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*ilzakirova@mail.ru*